**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«14» 07 2023 ел Яр Чаллы № 2252

2021 елның 2 июлендәге 1746 гомерлы «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне, аларның арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукын гамәлгә ашырганда, милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»на үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын актуальләштерү максатында һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары нигезендә, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» Башкарма комитетның 2022 елның 14 мартындагы 700 номерлы карарына таянып,

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2021 елның 2 июлендәге 1746 гомерлы «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәтне, аларның арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукын гамәлгә ашырганда, милеккә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»на түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.9.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.9.2. Муниципаль милектә булган һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан мондый милекне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда сатып алынган арендага алынган милек өчен түләү бер үк вакытта яки ваклап түләү рәвешендә айлык яки квартал саен түләнә торган түләүләр рәвешендә тигез өлешләрдә башкарыла.»;

2.9.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.9.3. Мондый милек өчен түләүне кичектереп тору срогы, аны сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда, муниципаль хокукый акт белән билгеләнә, әмма күчемсез милек өчен биш елдан да кимрәк һәм күчемле милек өчен өч елдан да кимрәк булырга тиеш түгел.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны ТР Тукай муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин